| МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** | Казан ш. | **БОЕРЫК** |
| _17.03.2022_ | | ___197-п___ |

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү турында карарлар кабул итү комиссиясе турында

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Татарстан Республикасы территориясендә җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы нигезләмә нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү турында карарлар кабул итү комиссиясен төзергә.

2. Кушымталарда бирелгәннәрне расларга:

2.1. Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү турында карарлар кабул итү комиссиясе турында нигезләмә;

2.2. Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү турында карарлар кабул итү комиссиясенең составын.

3. Хокукый тәэминат бүлегенә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И.И. Гобәйдуллинга йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
2022 елның 17 мартындагы
197-п номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү турында карарлар кабул итү комиссиясе турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү турында карарлар кабул итү комиссиясен (алга таба – Комиссия) формалаштыру һәм аның эшчәнлек башкару тәртибе билгеләнә.

1.2. «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – «Җир асты байлыклары турында» РФ Законы) $12^1$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензиягә (алга таба – Лицензия) үзгәрешләр кертү турында һәм лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү турында карарлар кабул итү Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Министрлык) төзи торган комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.3. Комиссия үз эшчәнлегендә «Җир асты байлыклары турында» РФ Законына, «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 12 октябрендәге 715 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләш-терү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү тәртибенә, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсенә кагылышлы башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.4. Комиссия лицензияләргә үзгәрешләр кертү һәм лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү буенча Министрлыкка йөкләнгән вәкаләтләрне тәэмин итү максатларында төзелгән коллегиаль орган булып тора.

1.5. Лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү өчен Министрлыкка тапшырылган гаризалар (алга таба – гариза) әлеге Нигезләмә нигезендә каралырга тиеш.

1.6. Комиссия рәисе, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

Комиссия составы Министрлыкның штат хезмәткәрләреннән төзелә. Комиссия әгъзаларының саны 11 кеше булырга тиеш.

1.7. Комиссия эшен рәис – җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләрен алып баручы Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары җитәкли. Комиссия рәисе урынбасары булып җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсе башлыгы тора.

1.8. Комиссия рәисе:

- Комиссия утырышын җитәкли һәм үткәрә;
- Комиссия сәркатибен билгели;
- Комиссия карарын раслый.

1.9. Комиссия рәисе булмаганда аның функцияләрен Комиссия рәисе урынбасары башкара.

1.10. Комиссия утырышлары турыдан-туры һәм (яки) видеоконференцэлемтә ярдәмендә үткәрелә.

1.11. Комиссия утырышларында гаризалар һәм аларга теркәп тапшырыла торган документлар һәм белешмәләр карала. Комиссия утырышлары гаризалар керүгә карап үткәрелә.

1.12. Комиссия эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итү комиссия сәркатибенә йөкләнә.

## II. Комиссиянең эш тәртибе. Комиссия тарафыннан карап тикшерү өчен, лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү буенча документлар әзерләү

2.1. Комиссия сәркатибе әлеге Нигезләмәнең 1.12 пункты нигезендә, лицензияләргә үзгәрешләр кертү һәм лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү буенча документлар комплектын әзерли, ул түбәндәге документларны һәм белешмәләрне үз эченә ала:

1) җир асты байлыкларыннан файдаланучы (мөрәҗәгать итүче һәм үзгәртеп рәсмиләштерелә торган лицензия буенча җир асты байлыкларыннан файдаланучы) турында белешмәләр, шул исәптән юридик зат өчен – тулы исеме, аның оешту-хокук рәвеше, төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең тәңгәллек номеры, шәхси эшкуар өчен – шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең тәңгәллек номеры, ә чит ил заты өчен – тиешле чит ил дәүләте законнары нигезендә салым түләүченең тәңгәллек номеры;

2) җир асты байлыклары кишәрлегенең исеме һәм аның геологик

билгеләмәләре, җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан элек башкарылган Җир асты байлыкларыннан файдалану буенча федераль агентлыкның Җир асты байлыкларыннан файдалану һәм дәүләт мәгълүмат ресурслары федераль агентлыгының федераль мәгълүмат системалары белешмәләре буенча лицензиядә каралган җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану шартлары турында кыска белешмәләр;

3) лицензия күчермәсе;

4) лицензиягә үзгәрешләр кертү нигезе турында мәгълүмат һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, шулай ук аларга үзгәрешләр кертү тәртибендә каралган, лицензиягә үзгә-решләр кертү процедурасын башлап җирү өчен нигез булып торган документлар;

5) лицензияне яңадан рәсмиләштерү нигезе турында мәгълүмат һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән Татарстан Респуб-ликасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдала-нуга лицензияләрне рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, шулай ук аларга үзгәрешләр кертү тәртибендә каралган, лицензияне яңадан рәсмиләштерү процедурасын башлап җирү өчен нигез булып торган документлар.

Комиссия сәркатибе әлеге Нигезләмәнең 1.12 пункты нигезендә Министрлык карамагындагы учреждениеләрдән һәм чит оешмалардан Комиссия утырышына әзерләнү өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны соратып алырга хокуклы.

2.2. Комиссия сәркатибе әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктында каралган лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү буенча документлар комплектын Комиссиягә тапшыра:

1) лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү очрагында гариза һәм аңа теркәп бирелә торган документлар һәм белешмәләр теркәлгәннән соң 7 эш көне эчендә;

2) техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны теркәгәннән соң яки Министрлык тарафыннан техник хатаны ачыклаганнан соң 5 эш көне эчендә;

3) Министрлык тарафыннан лицензия эчтәлеген «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законы яисә башка федераль законнар таләпләренә туры китерү турында карар кабул ителгәннән соң 20 эш көне эчендә;

4) Министрлык адресына юридик затның – җир асты байлыкларыннан файдаланучының исемен үзгәртү турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүмат кергән көннән соң 10 эш көне эчендә.

2.3. Комиссия сәркатибе лицензияләргә үзгәрешләр кертү һәм лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү буенча документлар комплекты нигезендә Комиссия утырышының көн тәртибе проектын әзерләүне гамәлгә ашыра.

Комиссия сәркатибе Комиссиянең барлык әгъзаларына электрон почта адресларына яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасы (ЕМСЭД) аша яисә теләсә кайсы башка үтемле ысул белән әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктында

каралган белешмәләрне үз эченә алган, әзерләнгән Комиссия утырышының көн тәртибе проектын һәм Комиссия утырышын үткәрү турында белдерүне Комиссия утырышы көненә кадәр 3 эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрә.

Комиссия утырышын үткәрү турында белдерүдә Комиссия утырышын үткәрү датасы һәм урыны, Комиссия әгъзаларының һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучының утырышта (турыдан-туры һәм (яки) видеоконференцэлемтә кулланып) катнашу ысулы турында белешмәләр булырга тиеш.

Комиссия сәркатибе әлеге пунктның өченче кызыл юлында каралган Комиссия утырышын үткәрү турында белдерүне җибәргән көнне Комиссия әгъзаларын мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан тапшырылган документлар һәм белешмәләр белән таныштыру мөмкинлеген тәэмин итә.

## III. Лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү буенча документларны Комиссия тарафыннан карау

3.1. Комиссия утырышында лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү буенча әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктында каралган документлар комплектын «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының $12^1$ статьясындагы бишенче өлешендә каралган лицензиягә үзгәрешләр кертү өчен нигезләр булу (булмау) предметына һәм лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү өчен «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының $12^1$ статьясындагы уникенче өлешендә һәм «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының $17^1$ статьясының беренче өлешендә каралган нигезләрнең булу (булмавы) предметына карау гамәлгә ашырыла.

3.2. Әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктында каралган документлар комплектын караганда, Комиссия әгъзалары Комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча тавыш бирергә яисә аларның һәркайсы буенча тавыш бирүдән тыелырга, карап тикшерүгә тәкъдим ителгән документлар комплектының эчтәлеге белән танышырга, Комиссия утырышы беркетмәсенә теркәлә торган аерым фикер белдерергә хокуклы.

Комиссия утырышы Комиссия әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше булган очракта хокуклы була. Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, Комиссия рәисе тавышы, ә ул булмый торганда, Комиссия рәисе урынбасарының тавышы хәлиткеч булып тора.

3.3. Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 401 статьясындагы 3 пункты нигезендә, Комиссия утырышын билгеләнгән көнне үткәрүгә комачаулаучы шартлар барлыкка килгәндә яисә Комиссия утырышы өчен кворум булмаса (ә ул булмаса – Комиссия рәисе урынбасары) Комиссия рәисе тарафыннан утырышны уздыру вакытын, ләкин биш эш көненнән дә артык булмаган чорга гына, күчерү турында карар кабул ителә.

3.4. Лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү буенча әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктында каралган документлар комплектын карау барышында Комиссия тарафыннан «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $12^1$ статьясының бишенче өлешендәге 2, 3, 6-8 пунктларында каралган башка нигезләр булуы билгеләнсә, Комиссия әлеге өстәмә нигезләр буенча

лицензиягә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итә.

3.5. Җир асты байлыкларыннан файдаланучы затның яисә Министрлыкның лицензиягә үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәре лицензиягә үзгәрешләр кертүнең «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $12^{1}$ статьясында каралган нигезләргә һәм (яки) «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 23 статьясында каралган җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау таләпләренә һәм (яки) «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $23^{2}$ һәм $36^{1}$ статьяларында каралган, расланган проект документларына һәм (яки) файдалы казылма запасларына һәм җир асты суларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә, файдалануга тапшырыла торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турында «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 29 статьясында каралган геологик мәгълүматка туры килмәсә, Комиссия җир асты байлыкларыннан файдаланучы яки Министрлык тарафыннан тәкъдим ителә торган үзгәрешләрне лицензиягә кертүдән баш тарту турында карар кабул итә.

3.6. Җир асты байлыкларыннан файдаланучы затның яисә Министрлыкның лицензиягә үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәре лицензиягә үзгәрешләр кертүнең «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $12^{1}$ статьясында каралган нигезләргә, җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау таләпләренә һәм (яки) «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $23^{2}$ һәм $36^{1}$ статьяларында каралган, расланган проект документларына һәм файдалы казылма запасларына һәм җир асты суларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсенә, файдалануга тапшырыла торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турында «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 29 статьясында каралган геологик мәгълүматка туры килсә, Комиссия җир асты байлыкларыннан файдаланучы яки Министрлык тарафыннан тәкъдим ителә торган үзгәрешләрне лицензиягә кертү турында карар кабул итә.

3.7. Комиссия утырышында лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү буенча документларны караганда, Комиссия шулай ук җир асты байлыкларыннан тиешле файдаланучыга карата контроль (күзәтчелек) чаралар актларының, шулай ук тиешле җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан ачыкланган бозуларны (булган очракта) бетерү турында күрсәтмәләр булуын да исәпкә ала.

3.8. Лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү буенча әлеге Нигезләмәнең 2.1 пунктында каралган документлар комплектын карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларны кабул итәргә хокуклы:

1) лицензиягә үзгәрешләр кертү турында;

2) лицензиягә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында;

3) лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында;

4) лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында.

## IV. Лицензиягә үзгәрешләр кертү (үзгәрешләр кертүдән баш тарту) турында яисә лицензияне яңадан рәсмиләштерү (яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту) турында Комиссия карарын рәсмиләштерү

4.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.8 пунктында каралган карар, «Электрон имза

турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә, утырышта катнашкан барлык әгъзалар тарафыннан имзаланган электрон документ рәвешендә Комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

4.2. Комиссия утырышы беркетмәсе әлеге Тәртипнең 4.1 пунктында каралган тәртиптә, Комиссия утырышы уздырылганнан соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча Комиссия әгъзалары тарафыннан рәсмиләштерелә һәм имзалана.

4.3. Лицензиягә үзгәрешләр кертү яки лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында каралган һәр мәсьәлә буенча Комиссия утырышы беркетмәсендә күрсәтелә:

1) җир асты байлыкларыннан файдаланучы (лицензия яңадан рәсмиләштерелгән очракта, мөрәҗәгать итүче һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучы) турында белешмәләр, шул исәптән юридик зат өчен – тулы исеме, аның оештухокук рәвеше, төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең тәңгәллек номеры, шәхси эшкуар өчен – шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең тәңгәллек номеры, ә чит ил заты өчен – тиешле чит ил дәүләте законнары нигезендә салым түләүченең тәңгәллек номеры;

2) лицензиянең дәүләт теркәү номеры һәм аны дәүләт теркәвенә алу датасы, җир асты байлыклары кишәрлегенең исеме, җир асты байлыкларыннан файдалану төре;

3) лицензиягә үзгәрешләр кертү нигезен күрсәтү;

4) лицензияне яңадан рәсмиләштерү нигезләрен күрсәтү;

5) җир асты байлыкларыннан тиешле файдаланучыга карата контроль (күзәтчелек) чаралар актлары булу турында мәгълүмат, шулай ук җир асты байлыкларыннан тиешле файдаланучыга ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү турында бирелгән күрсәтмәләр (булган очракта);

6) «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $23^2$ һәм $36^1$ статьяларында каралган проект документларының белешмәләре (лицензиягә үзгәрешләр кертелгән очракта);

7) җир асты байлыкларыннан файдаланучының лицензиядә каралган җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану шартларын үтәве турында белешмәләр (лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү очрагында);

8) лицензиянең үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә торган бүлекләре (лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү очрагында);

9) лицензиягә тәкъдим ителә торган үзгәрешләрнең эчтәлеге, әлеге үзгәрешләрнең кирәклеген күрсәтү (лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелгән очракта);

10) әлеге Нигезләмәнең 3.8 пунктында каралган Комиссия карары.

Комиссия утырышы беркетмәсенә Комиссия әгъзаларының аерым фикере (булган очракта) теркәп куела.

4.4. Комиссия сәркатибе, әлеге Нигезләмәнең 1.12 пункты нигезендә, Комиссия әгъзалары кул куйган көннән алып биш эш көне эчендә, Комиссия утырышы беркетмәсендә билгеләнгән тәртиптә, аны «Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү буенча автоматлаштырылган система» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыра.

4.5. Комиссия утырышының расланган беркетмәсен урнаштырганнан соң өч эш көне дәвамында «Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү буенча автоматлаштырылган система» федераль дәүләт мәгълүмат системасында мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдаланучының шәхси кабинетын кулланып яисә гаризада күрсәтелгән электрон почта адресы буенча кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

4.6. Комиссия лицензиягә үзгәрешләр кертү турында карар кабул иткән очракта, Комиссия сәркатибе Комиссия утырышы беркетмәсенә кул куйганнан соң биш эш көне эчендә җир асты байлыкларыннан файдаланучының шәхси кабинеты аша һәм (яки) аның электрон почта адресын кулланып, яисә гаризада күрсәтелгән адрес буенча почта аша җибәреп, лицензиягә кертелә торган үзгәрешләр белән аның ризалыгын алу яки лицензиягә кертелә торган үзгәрешләр белән килешүдән баш тарту өчен Комиссия тарафыннан кабул ителгән карар турында мәгълүмат җибәрә. Лицензиягә кертелә торган үзгәрешләр турында мәгълүмат лицензия бүлегенең гамәлдәге редакциясен һәм аңа тәкъдим ителә торган үзгәрешләрне күрсәтеп, чагыштырма таблица (алга таба – чагыштырма таблица) рәвешендә тапшырыла.

Җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат, әлеге пунктның беренче кызыл юлында күрсәтелгән мәгълүматны җибәргән көннән соң 10 эш көне дәвамында, үзенә тапшырылган, җир асты байлыкларыннан файдаланучы затның вәкаләтле вәкиле тарафыннан «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган чагыштырма таблицаны җир асты байлыкларыннан файдаланучының Шәхси кабинетыннан файдаланып, Министрлык адресына һәм (яки) Министрлыкның электрон почта адресына җибәрү юлы белән лицензиягә кертелә торган үзгәрешләр белән риза булуын белдерә.

Җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат, әлеге пунктның беренче кызыл юлында күрсәтелгән мәгълүматны җибәргән көннән соң 10 эш көне дәвамында, җир асты байлыкларыннан файдаланучы затның вәкаләтле вәкиле тарафыннан «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган лицензиягә кертелә торган үзгәрешләрне килештерүдән баш тарту турындагы хатны җир асты байлыкларыннан файдаланучының Шәхси кабинетыннан файдаланып, Министрлык адресына һәм (яки) Министрлыкның электрон почта адресына җибәрү юлы белән лицензиягә кертелә торган үзгәрешләрне килештерүдән баш тартуын белдерә.

Җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат тарафыннан әлеге пунктның икенче һәм өченче кызыл юллары нигезендә тапшырыла торган мәгълүматка, җир асты байлыкларыннан файдаланучы - юридик зат исеменнән эш итүгә затның вәкаләтләрен раслый торган документ (җир асты байлыкларыннан файдаланучы җитәкчесен билгеләү яисә сайлап кую турында карар күчермәсе яисә боерык күчермәсе) теркәлә. Әгәр җир асты байлыкларыннан файдаланучы исеменнән башка зат эш итсә, әлеге мәгълүматка шулай ук җир асты байлыкларыннан файдаланучы зат исеменнән (булган очракта) һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучы затның җитәкчесе яки җир асты байлыкларыннан файдаланучының башка вәкаләтле җитәкчесе тарафыннан имзаланган гамәлләр башкаруга

ышанычнамәнең төп нөсхәсе булырга тиеш. Әлеге ышанычнамә җир асты байлыкларыннан файдаланучының вәкаләтле җитәкчесе тарафыннан имзаланган очракта, шулай ук әлеге затның вәкаләтләрен раслаучы документ та теркәлә.

Җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан әлеге пунктның беренче кызыл юлында күрсәтелгән мәгълүматны юллау көненнән башлап 10 эш көне эчендә әлеге пунктның икенче кызыл юлы нигезендә имзаланган чагыштырма таблица тапшырылмаса, лицензиягә булган үзгәрешләр килештерелмәгән булып санала.

4.7. Лицензиягә үзгәрешләр кертү аңа кушымта белән рәсмиләштерелә.

Лицензиягә кушымта XML форматындагы файл рәвешендә, «Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү буенча автоматлаштырылган система» федераль дәүләт мәгълүмат системасына интеграцияләнгән махсус программа тәэминатын кулланып, җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 4.5 пунктының икенче кызыл юлы нигезендә имзаланган чагыштырма таблица алынган көннән башлап яки әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктында каралган Комиссия утырышы беркетмәсен рәсмиләштергән көннән башлап җиде эш көненнән дә соңга калмыйча рәсмиләштерелә.

Җир асты байлыкларыннан файдаланучы, җир асты байлыкларыннан файдаланучының шәхси кабинетыннан файдаланып, Министрлыкка ирекле формада җибәрелгән тиешле гариза нигезендә, шәхсән яки почта аша лицензия алырга хокуклы.

Лицензиягә кушымта нөсхәсе кәгазьдә Министрлык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә раслана.

Министрлыкның лицензияләү өчен җаваплы вазыйфаи заты җир асты байлыкларыннан файдаланучының вәкаләтле вәкиленә лицензияне, алу турында имзалатып, турыдан-туры тапшыра яисә җир асты байлыкларыннан файдаланучының әлеге пунктның дүртенче кызыл юлында каралган гаризасы алынган көннән башлап 10 эш көне эчендә, ләкин лицензиягә кушымтаны дәүләт теркәвенә алган көннән башлап биш эш көненнән дә иртәрәк түгел, лицензиягә кушымтаның кәгазь нөсхәсен тапшыру турында белдерү белән почта аша заказлы юллама белән җибәрә.

4.8. «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының $12^1$ статьясының бишенче өлешендәге 1-5 пунктларында каралган нигезләр буенча лицензиягә үзгәрешләр кертү җир асты байлыкларыннан файдаланучы белән килештерелмәгән булса, әлеге Нигезләмәнең 4.6 пунктында каралган лицензиягә кушымта рәсмиләш-терелми.

4.9. Лицензия яңадан рәсмиләштерелгән очракта, лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында карар кабул итүгә нигез булган Комиссия утырышының расланган беркетмәсен «Җир асты байлыкларыннан файдаланучыны лицензияләү буенча автоматлаштырылган система» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру билгеләнгән тәртиптә яңадан рәсмиләштерелгән лицензияне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү нигезе булып тора.

## V. Лицензиягә үзгәрешләр кертүдән баш тарту, лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турындагы карарга карата шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүче Министрлыкның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына, шулай ук лицензиягә үзгәрешләр кертүдән яки лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турындагы Комиссия карарына Министрлык җитәкчесе (җитәкче урынбасары) исеменә шикаять бирү юлы белән шикаять бирергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче карар белән килешмәгән очракта, ул аңа административ яки суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать ресурслары
министрлыгының __________
№______ боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына лицензиягә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасының җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү турында карарлар кабул итү комиссиясенең составы

| | |
|---|---|
| Гобәйдуллин Илнур Ирек улы | Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары; |
| Вахитов Самат Таһир улы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсе җитәкчесе – Комиссия рәисе урынбасары; |
| Игнашева Анна Вячеславовна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы белгече – Комиссия сәркатибе; |
| Ахманова Татьяна Петровна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының углеводород чималы геологиясе бүлеге җитәкчесе; |
| Васильева Татьяна Леонидовна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының гидрогеология һәм судан файдалануны җайга салу бүлеге җитәкчесе; |
| Лукина Людмила Александровна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлеге җитәкчесе; |
| Пестова Екатерина Николаевна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы белгече |
| Полюшков Алексей Сергеевич | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе җитәкчесе |
| Ткачук Алексей Иванович | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының хокукый тәэмин итү бүлеге җитәкчесе |
| Чинарев Алексей Михайлович | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе җитәкчесе; |
| Шутникова Светлана | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать |

| | |
|---|---|
| Анатольевна | ресурслары министрлыгының каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесе. |